Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LVIII-3**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 7 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2022 елның 7 июлендәге «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» XXIII-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләр тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2022 елның 7 июлендәге «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» XXIII-3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап органы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 40 740 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 36 667 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы рәисе | 36 667 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 32 931 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы аудиторы | 28 008 |

1.2. 3 нче кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре

| N п/п | Вазыйфаның аталышы | Айлык вазыйфаи хезмәт хакы, сумнар |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 40 012 |
| 2. | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 36 319 |
| 3. | Совет аппараты җитәкчесе | 36 319 |
| 4. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 36 011 |
| 5. | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 35 857 |
| 6. | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 32 933 |
| 7. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 29 240 |
| 8. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 28 008 |
| 9. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы урынбасары | 27 701 |
| 10. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 24 469 |
| 11. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе | 24 469 |
| 12. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 24 469 |
| 13. | Сектор мөдире | 22 622 |
| 14. | Баш белгеч | 21 699 |
| 15. | Әйдәүче белгеч | 20 160 |

1.2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата кызыксындыру күләмнәре һәм тәртибе» дигән 7 нче кушымтадагы «41» санын «58» санына алыштырырга;

1.3. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе» дигән 17 нче кушымтадагы 1 пунктның 6 пунктчасында «41» санын «58» санына алыштырырга;

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үзләренең хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның үз көчен (йогынтысын) 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерүен (таратуын) билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов